ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17 нче йорт. Тел/факс.: 3-13-44, 3-15-05.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/факс.: 3-13-44, 3-15-05.

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

от 14.03.2016 № ПГ-16

**Актаныш муниципаль районында 2016 ел – Россиядә кино елы, Татарстанда сусаклагычлар елы, Актаныштa Бию елы унаеннан авыл, район үзәге үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсын үткәрү турында**

Актаныш муниципаль районында үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсын ныклы әзерлек белән үткәрү өчен

к а р а р б и р ә м:

1. Актаныш муниципаль районында 2016 нчы елның 28 нче март – 01 май көннәрендә үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсын үткәрергә.

2. Авыл җирлеге башлыкларына, хуҗалык, предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә хезмәт коллективлары алдында торган бурычларны хәл итү шартларында, ныклы әзерлек, югары дәрәҗәдә оешканлык белән үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсында катнашуны тәкъдим итәргә.

3. Эчке эшләр Министрлыгының Актаныш районы буенча бүлек җитәкчесе Р.Р.Гәйнетдиновка үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсын үткәрү көннәрендә җәмәгать тәртибен саклау буенча өстәмә чаралар оештыруны тәкъдим итәргә.

4. 2016 ел – Россиядә кино елы,Татарстанда сусаклагычлар елы, Актаныштa бию елы унаеннан авыл, район үзәге үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсын үткәрү турында Нигезләмәне расларга (кушымта).

Муниципаль район Башлыгы Ф.М.Камаев

Гәбделхәев И.И.
3-11-55

Актаныш муниципаль районы
Башлыгының
“14” 03 2016 елның
ПК-16 санлы карарына
кушымта

**2016 ел – Россиядә кино елы, Татарстанда сусаклагычлар елы, Актанышта бию елы унаеннан авыл, район үзәге үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсын үткәрү турында нигезләмә**

**Конкурсны гамәлгә куючы**

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты.

**Оештыручылар**

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты;
Район Башкарма комитетының социаль агарту бүлеге;
“Актаныш район мәдәният йорты” МБУ.

**Смотрның максаты**

- Районда халык иҗатын тагын да үстерү, сәләтлеләрне барлау һәм ачыклау;
- үз милләтебез моңына,районыбыздагы авыллар тарихына, атамаларына игътибар арттыру;
- халкыбыз җырларына яңадан-яңа кызыксыну уяту;
- яшьләр арасында халкыбыз уен кораллары һәм җырлары аша туган җиргә карата горурлык хисе тәрбияләү;
- милли мәдәниятебезнең өзелмәс чылбырын булдыру;
- телебезнең бай лексик составын, сыгылмалылыгын, аһәңен дөрес фонетик яңгырашта сүз сәнгате аша сәхнәдән җиткерү;
- төрле милләт халыкларының гореф - гадәтен, яшәешен, омтылышларын аларның биюләре аша чагылдыру;
- өлкән буын кешеләренә карата игелеклелек хисләрен яңарту;
- тарихи мирас белән кызыксыну, үткәннәр белән киләчәк җепләрен ныгыту.

**Смотрның бурычы**

- Халык иҗатын , мәдәни һәм ял эшчәнлегенең төрле формаларын саклау һәм үстерү;
- халыкның мәдәни-ял эшчәнлегенең төрлелеген тәэмин итү;
- районда халык иҗатын тагын да үстерү;
- яшь буынга патриотик һәм әхлак тәрбиясе бирүне арттыру;
- үзешчән сәнгать коллективларының башкару осталыгын арттыру.

**Смотрның шартлары:**

- смотр концертында түбәндәге жанрлар булуы шарт:

**Авыл үзешчән сәнгать коллективлары буенча:**

1. Катнаш вокаль ансамбльләр чыгышы “Авыл җыры” (һәр җирлек үз авылына багышланган җыр җырларга, авылның үз җырын булдырырга тиеш). Ансамбльдә кеше саны 10 нан да ким булмасын.
2. Аерым җырчылар ( хатын-кызлар,ир-егетләр, 4 кешегә кадәр)
3. Катнаш дуэт (2дуэтка кадәр).
4. Нәфис сүз. “Тукай тәлгәшләре” яки “Дүрт тараф – дүрт елга” (Агыйдел, Кама, Ык, Сөн һәм башка Актанышыбызда , авылларыбызда юл ярган елгалар турында яки Габдулла Тукай шигырьләрен ялгыз яисә композицион (4 кешедэн дэ ким булмаска тиеш) рәвештә башкару).
5. Бию коллективлары чыгышлары. 2 бию - татар һәм башка миллэт биюе . Бию ансамбле 5-6 пардан да ким булмаска тиеш.
6. Фольклор чыгыш ( борынгы киенү үрнәкләрен, борынгы көйләрне, биюләрне, җырларны, җирлеккә кагылышлы йолаларны, диалекталь сөйләмне, борынгы инструментларны (бигрәк тә тальян, саратский гармун, сорнай, домбра, мандолина,скрипка, кубыз, кашык,х.б. кулланып куелган музыкаль чыгыш - 5-6 минут. А.Файзрахмановның фольклор ансамбле форматында). Фольклор ансамбльдә катнашучылар саны 10 нан да ким булмаска тиеш.

**Район үзәгендәге оешма, предприятиеләренең үзешчән сәнгать коллективлары буенча:**

1. Катнаш вокаль ансамбльләр чыгышы “Безнең яраткан җырлар” (рус киноларыннан яисэ татар спектакльләреннән яраткан, таныш, популяр җырлар). Ансамбльдә кеше саны 10 нан да ким булмасын.
2. Аерым җырчылар ( хатын-кызлар,ир-егетләр, 2 кешегә кадәр).
3. Катнаш дуэт (2дуэтка кадәр).
4. Нәфис сүз. “Тукай тәлгәшләре” яки “Дүрт тараф – дүрт елга” (Агыйдел, Кама, Ык, Сөн һәм башка Актанышыбызда, авылларыбызда юл ярган елгалар турында яки Габдулла Тукай шигырьләрен ялгыз яисә композицион (4 кешедэн дэ ким булмаска тиеш) рәвештә башкару).
5. Бию коллективлары чыгышлары. 2 бию - татар һәм башка милләт биюе. Бию ансамбле 5-6 пардан да ким булмаска тиеш.
6. Фольклор чыгыш (борынгы киенү үрнәкләрен, борынгы көйләрне-биюләрне, җырларны, җирлеккә кагылышлы йолаларны, диалекталь сөйләмне, борынгы инструментларны (бигрәк тә тальян, саратский гармун, сорнай, домбра, мандолина, скрипка, кубыз һ.б. кулланып куелган музыкаль чыгыш - 5-6 минут. А.Файзрахмановның фольклор ансамбле форматында).Фольклор ансамбльдә катнашучылар саны 10 нан да ким булмаска тиеш.

**Искәрмә:** хатын-кызлардан гына торган коллективларга жанрларда ир-егетләрнең булуы шарт түгел.

- Смотрда катнашучыларның яше: 15 яшьтән .

**Бүләкләү:**

Жюри үзара килешеп коллективлар арасында урыннарны бүлешә һәм аерым номинацияләр билгели ала.

Нигезләмәгә
1нче санлы кушымта

**Актаныш муниципаль районында 2016 ел – Россиядә кино елы,Татарстанда сусаклагычлар елы, Актанышта Бию елы унаеннан авыл, район үзәге үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсының жюри составы:**

Жюри рәисе: район башкарма комитетының социаль- агарту бүлеге башлыгы - Габделхәев И.И.

Гайнетдинова А.Ф. – район мәдәният йорты директоры.
Мусин Р.М. - район мәдәният йорты хормейстеры.
Хөсәенов.И. - район мәдәният йорты балетмейстеры.
Мухаметова И.И. - район мәдәният йорты режиссеры.
Нажарова Р.Р. – район мәдәният йорты методисты.

Нигезләмәгә
2нче санлы кушымта

**Актаныш муниципаль районында 2016 ел – Россиядә кино елы,Татарстанда сусаклагычлар елы, Актанышта Бию елы унаеннан авыл үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсын үткәрү ГРАФИГЫ 2016 ел**

28 март – **Тат.Суксу зонасы :**
**Такталачык, Теләкәй,Бурсык, Мәсәде, Иске Кормаш, Чалманарат, Тат.Ямалы .**

29 март - **Пучы зонасы :**
**Түке, Айман, Усы, Әтәс, Күҗәкә.**

30 март – **Киров зонасы:**
**Байсар, Чуракай, Сәфәр, Аккүз, Яхшый.**

31 март - **Яңа Әлем зонасы**:
**Богады, Уразай, Кәзкәй,Актанышбаш, Аеш.**

Нигезләмәгә
3нче санлы кушымта

**Актаныш муниципаль районында 2016 ел – Россиядә кино елы,Татарстанда сусаклагычлар елы, Актанышта Бию елы унаеннан район үзәге үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсын ГРАФИГЫ 2016 ел**

1. Технологик техникум.
2. Социаль яклау бүлеге , ветераннар советы, инвалидлар оешмасы - 2 апрель
3. Телевидение, радио, газета, типография - 3 апрель
4. Актаныш муниципаль район Советы, Башкарма комитеты - 4 апрель
5. Авыл хуҗалыгы идарәсе,Ветеринария оешмасы,Статистика бүлеге - 5 апрель
6. Балалар иҗат үзәге, Балалар сәнгать мәктәбе, Үзәк китапханә - 6 апрель
7. Балалар бакчалары: ”Әтәчкәй”, “Ромашка”, “Алтын чәч”, “Кояшкай”, “Каенкай”, “Умырзая”, башлангыч мәктәп-балалар бакчасы - 7 апрель
8. “Лачын” Боз сарае, “Иман” спорт комплексы - 8 апрель
9. Кадет интернат -мәктәбе - 9 апрель
10. МНКТ, Нефтебаза - 10 апрель
11. “Коммунсервис -Актаныш” ҖЧҖ, Икмәк кабул итү пункты, Райгаз, Теплосервис ҖЧҖ - 11 апрель
12. Актаныш үзәк хастаханәсе, Аптека №73, “ВИТА” аптекасы, Санэпедимстанция - 12 апрель
13. АСШ №1- 15 апрель
14. АСШ №2 - 16 апрель
15. Сәләтле балалар өчен гимназия -интернат - 17 апрель
16. Татфондбанк, Сбербанк, Россельхозбанк, Ак барс банк - 9 апрель
17. ПМК, ПМК 6, ПМК 9, ҖЧҖ, АТП, Подстанция - 18 апрель
18. ЭЭМ Актаныш районы буенча бүлеге, ГИБДД, МЧС - 19 апрель
19. Миграция хезмәте, Салым инспекциясе, Казначалык, МФЦ, Росреестр - 20 апрель
20. Военкомат, Прокуратура, Район суд, Җәмәгать суды - 22 апрель
21. Пенсия фонды идарәсе, РУЭС, Почта элемтә бүлеге - 23 апрель
22. МТС ОАО “Ремтехсервис”, ООО Мехотряд, Агрегатный завод - 24 апрель
23. “Актаныш юллары” ДПМК(ООО “Юлчы”), ДУ Татавтодор, Камдорстрой - 25 апрель
24. Эшмәкәрләр (Шайхразиев Б.М.) - 26 апрель

Нигезләмәгә
4нче санлы кушымта

Актаныш районы авылларының һәм район үзәге оешма-предприятиеләре үзешчән сәнгать коллективлары смотр-конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты составы (килешү нигезендә)

| | |
|---|---|
| Бариев И. Ш. | Актаныш муниципаль район Башлыгы урынбасары , комитет рәисе |
| Фәттахов И. Э. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комитет рәистәше |
| Шәмсунова Л. Җ. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләре буенча урынбасары, комитет рәистәше |

Комитет әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Габделхәев И. И. | Актаныш муниципаль районы, башкарма комитеты социаль һәм агарту бүлеге җитәкчесе |
| Каюмова К. Р. | Актаныш муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Нурлыев Н. Г. | Актаныш районы Ветераннар советы җитәкчесе |
| Шаязданова Л. К. | «Актаныш районы балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе директоры |
| Гайнутдинова А. Ф. | «Актаныш район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе директоры |
| Мухаметова И. М. | «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе режиссеры |
| Тимиров А. И. | Актаныш авылы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Хөҗҗәтов И. Н. | “ТАТМЕДИА” ААҖ “Актаныш ММҮ” филиалы директоры. |